| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

______18.06.2021______ п.г.т.Алексеевское № __247____

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү Тәртибе турында**

Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны стимуллаштыру һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 135, 191 маддәләре нигезендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен кызыксындыруны оештыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү Тәртибен расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 18 июнендәге
247 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан акчалата бүләкләү рәвешендә грантлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

Грант бирүнең максаты - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләрен уздыру барышында югары күрсәткечләргә ирешкән иң актив механизаторларны мотивацияләү.

2. Грантлар авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә бирелә, ул район башкарма комитеты карары белән расланган.

3. Грантлар атна саен бирелә һәм, күмелгән һәм эшкәртелгән җир мәйданына карап, механизаторлар арасында бүленә (файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының аерым төркемнәре буенча, куәтенә һәм 180 ат көченнән кимрәк булган очракта).

4. Грант бирүнең нәтиҗәсе - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләрен уздыру барышында югары күрсәткечләр.

Грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр түбәндәгеләр:

тырмаланган һәм эшкәртелгән җир мәйданы күләме (файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының аерым төркемнәре буенча, югарырак егәрлеккә һәм 180 ат көченнән кимрәк булганда);

чәчелгән җир мәйданы күләме (чәчү комплексын яисә СЗ (СЗП) аерым-аерым файдаланып);

техник культуралар һәм кукуруз чәчелгән җир күләме.

5. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты Алексеевск муниципаль районы территориясендә язгы кыр эшләре чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлары) арасында конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә конкурс үткәрә.

6. Конкурс ел саен язгы кыр эшләре вакытында, 1 апрельдән 1 июньгә кадәр, һәр 7 көн эш вакыты белән, түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- «Туфракны тырмалауда эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Бөртекле культуралар чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор»;

- «Техник культуралар һәм кукуруз чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор»;

7. Катнашучыларга түбәндәге таләпләр куела:

7.1 «Туфракны тырмалауда эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә карата

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;

- югары егәрлеккә һәм 180 ат көченнән кимрәк булган (аерым) авыл хуҗалыгы техникасыннан файдаланып эшләр башкару;

7.2. «Бөртекле культуралар чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә;

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;

- чәчү комплексын яисә СЗ (СЗП) кулланып эшләр башкару (аерым-аерым);

7.3. «Техник культуралар һәм кукуруз чәчүдә эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә;

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яисә КФХ хезмәткәре;

- техник культуралар һәм кукуруз чәчкечләрен кулланып эшләр башкару.

8. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен түбәндәге составта конкурс комиссиясе төзергә:

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Гайнуллин О.А. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Мусин Г.К. | - Алексеевск муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Михайлов Ю.В. | - Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Поповнин В.В. | - Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Ибраһимова А.И. | - Алексеевск муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты (килешү буенча) |

9. Конкурсның һәр чорында катнашуга гаризалар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә отчет чорының соңгы эш көнендә түбәндәге электрон рәвештә бирелә: alekseevsk.alsu@tatar.ru. Җыелган гаризалар көн азагында конкурс комиссиясе рәисенә җибәрелә.

10. Комиссия утырышлары атна саен комиссия рәисе карары буенча уздырыла. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

11. Грантлар авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә, алар конкурс игълан ителгән айга кадәрге айның 1 нче числосына түбәндәге таләпләргә туры килә:

а) грант алучыларның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

б) грант алучыларның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмаска тиеш, аннан

әлеге тәртип нигезендә субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү планлаштырыла, һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдындагы башка срогы чыккан бурыч.

12. Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм алар арасында тырмаланган һәм эшкәртелгән җир мәйданына карап премияләр бүлә (файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының аерым төркемнәре буенча, югарырак куәткә һәм 180 ат көченнән кимрәк):

1 урын - 3000 (өч мең) сум;

2 урын - 2000 (ике мең) сум;

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм чәчелгән җир мәйданына карап (чәчү комплексын яисә СЗ (СЗП) аерым-аерым файдаланып) алар арасындагы премияләрне бүлә:

1 урын - 3000 (өч мең) сум;

2 урын - 2000 (ике мең) сум;

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

Комиссия конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели һәм алар арасындагы премияләрне, техник культуралар һәм кукуруз чәчелгән мәйданга карап, бүлә:

1 урын - 3000 (өч мең) сум;

2 урын - 2000 (ике мең) сум;

3 урын - 1000 (бер мең) сум.

13. Хезмәткәргә грант алудан баш тарту өчен аның әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве нигез була.

14. Башлык грантлары Алексеевск муниципаль районы бюджетында бирелгән максатчан финанс чараларыннан түләнә һәм авыл хуҗалыгы кадрларының һөнәри үсешен һәм квалификациясен стимуллаштыру өчен билгеләнгән.

15. Грантларны түләү грантлар тапшырганнан соң 15 эш көне эчендә грант алган затның банк счетына акчалар күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.Ә.Йосыпова**